**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«19» март, 2026 ел

№ 178-п

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру турында» 2025 елның 8 декабрендәге 928-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм сәламәтләндерү турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы, «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү «Дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы, «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 елның 9 сентябрендәге 754 карарларын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру турында» 2025 елның 08 декабрендәге 928-п номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Питрәч муниципаль районының балаларның һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерү, мәшгульлеге программасын 2026 елга (1 нче кушымта) кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. Ведомствоара комиссия составыннан кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә (3 нче кушымта) Е.Д. Лифанованы чыгарырга һәм «Питрәч муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Чемеровны кертергә.

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә: «http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А. Харитоновага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов